**<u>Муса Җәлил</u>**

## Төрмә сакчысы

*(«Казан»)*
*(Ядкарь хан монологы)*

Йортым ишеген саклап, сакчы йөри,
Җиңнәрендә «сөңге» билгесе.
Йөрәгемә кадак каккан кебек
Аның салмак атлап йөреше.

Куркып аныңерткыч күзләреннән,
Тынып калган тирә-әйләнә.
Җир сыкрыйдыр кебек ул басканга,
Кояш аңа артын әйләнә.

Кешелеккә ямьсез бүкәй булып,
Кулларына тотып камчысын,
Ул утыра менә төрмә саклап, —
Коллык, вәхшәт, үлем ялчысы.

Тоткыннарның йөрәк итен чукып
Үтә аның козгын тормышы.
Аңа икмәк — кан һәм күз яшьләре,
Мәхкүмнәрнең соңгы сулышы.

Белсә иде шакшы бу колларның
Күпме гомерләрне буганын,
Җир күтәрмәс иде бу кешене,
Кояш бирмәс иде нурларын!

**1943 ел**